РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, с.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова, д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «10» декабря 2020 года № 560

2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районында халыкны
наркотиклаштыруны (наркотизацияләү)
профилактикалау муниципаль программасын
раслау турында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ:**

1.2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны (наркотизацияләү) профилактикалау муниципаль программасын расларга

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов

Расланган
ТР Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «10» декабре 500 №
карары

# 2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны (наркотизацияләү) профилактикалау муниципаль программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны (наркотизацияләү) профилактикалау муниципаль программасы (алга таба-Программа) |
| Дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның координаторы (җаваплылысы) | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Россия эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы буенча бүлекчәсе, «Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәдәният бүлеге» МКУ, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әлки муниципаль районы буенча социаль яклау бүлеге, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының финанс бюджет палатасы, Әлки муниципаль районының «Әлки хәбәрләре»газетасы. |
| Программаның максаты һәм бурычлары | Программаның максаты-Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында наркотикларны законсыз тарату һәм медицина бәйле булмаган куллану масштабларын киметү.<br>Программаның бурычлары:<br>хокук саклау органнарының наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча көчләрен активлаштыру;<br>дәвалау һәм реабилитацион ярдәм системасын камилләштерү;<br>балаларны һәм яшьләрне спорт, физик тәрбия һәм спорт түгәрәкләрендә даими шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру;<br>халыкта наркотиклар куллануга тискәре караш һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | Программаны тормышка ашыру 2021-2023 еллар дәвамында башкарылачак |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Район халкын наркотиклаштыруны профилактикалау буенча программа чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 135 мең сум кирәк |
| Программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2023 елда 2020 елга карата түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>дәвалау һәм тернәкләндерү узган наркомания белән авыручылар санын арттыруны тәэмин итү(процент):<br>2021 елда-104,<br>2022 елда-105<br>2023 елда-106<br>физик культура һәм спорт түгәрәкләрендә даими рәвештә шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр санын арттыру (процент):<br>2021 елда-109<br>2022 елда-110;<br>2002 елда-111<br>сәламәт яшәү рәвешенә юнәлтелгән балалар һәм яшьләр санын арттыру (процент):<br>2021 елда-104,<br>2022 елда-105<br>2023 елда-103 |

## I. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманы характерлау

Әлки муниципаль районында наркотик матдәләрдән явызларча файдалануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча максатчан эш Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 18 февралендәге 49 номерлы карары белән расланган 2014-2020 елларга Татарстан Республикасында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалауның муниципаль программасы нигезендә алып барыла.

Әлеге программа нигезендә:

- халыкны наркотиклаштыруга каршы тору чараларының нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән берничә документлар эшләнде;

-спорт учреждениеләре челтәрен үстерүгә, яшүсмерләр һәм яшьләрнең социаль-позитив ялын оештыру өчен яңа секцияләр һәм түгәрәкләр ачуга җитди игътибар бирелә;

- тематик акцияләр, марафоннар, концертлар үткәрелә, массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар бастырыла;

- эштә наркотикларга каршы эчтәлекле күрсәтмә агитация чаралары кулланыла: плакатлар, брошюралар һ. б.;

- наркотик матдәләр кулланучыларны ачыклау нәтиҗәлелеген арттыру өчен шартлар тудырыла;

-наркотик матдәләрнең законсыз әйләнешенә һәм куллануга каршы көрәш бүлекчәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге һәм хокук саклау органнарының матди-техник базасын ныгыту артты.

Наркоманияне нәтиҗәле профилактикалауны оештыру мөһим юнәлеш булып тора. Районның уку йортлары методик материал белән җиһазландырылган, төрле катлам халык өчен белем бирү проектлары һәм программалары гамәлгә кертелә.

Кабул ителгән гамәлләргә карамастан, наркомания проблемасы алдынгы урында һәм халыкның сәламәтлегенә һәм милли куркынычсызлыкка глобаль куркыныч булып тора.

Әлеге Программа кысаларында наркомания таралуга каршы көрәшнең адекват һәм нәтиҗәле чараларын гамәлгә ашыру буенча көчләрне арттыру планлаштырыла.

Программаны эшләгәндә наркотиклардан явызларча файдалануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча республика тәҗрибәсе, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, практик хезмәткәрләрнең тәкъдимнәре исәпкә алынды.

## II. Программаның төп максаты, бурычлары һәм сроклары, шулай ук максатлар һәм бурычлар киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары

Программаның максаты - 2020 елга карата, 2023 елга, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында наркотикларны законсыз тарату һәм медицинага бәйле булмаган куллану масштаблары үсешенә юл куймау.

Программаның максатына ирешү түбәндәге юнәлешләр буенча чараларны баланслы яраштыру нигезендә гамәлгә ашырыла:

а) Республикада легаль булмаган җитештерү инфраструктурасын, наркотикларны ташу һәм таратуны киметү юлы белән наркотиклар тәкъдимен кыскарту, наркотик матдәләр, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары керүгә юл куймау, шулай ук легаль булмаган көчле тәэсир итүче матдәләрнең законсыз әйләнешен кертүне, наркотикларның яңа төрләре әйләнешен, шулай ук медицинага бәйле булмаган контрольсез психоактив чаралар һәм матдәләр куллануны киметү;

б) профилактик, дәвалау һәм реабилитация эше системасын камилләштерү, җәмгыятьтә наркотикларны медицинага бәйле булмаган куллануга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру юлы белән наркотикларга ихтыяҗны киметү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

хокук саклау органнарының наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча көчләрен активлаштыру;

дәвалау һәм реабилитацион ярдәм системасын камилләштерү;

балаларны һәм яшьләрне спорт, физик культура һәм спорт түгәрәкләрендә даими шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

халыкта наркотиклар куллануга тискәре караш һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру.

Медицинага бәйле булмаган наркотиклар куллануны профилактикалау системасын формалаштыруда барлык дәрәҗәдәге дәүләт

хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар, гражданнар, шул исәптән мәгариф, медицина һәм мәдәни-агарту учреждениеләре белгечләре, яшьләр оешмалары волонтерлары катнаша.

Медицинага бәйле булмаган наркотиклар куллануны профилактикалау чаралары халыкның барлык категорияләре өчен, беренче чиратта, имин булмаган гаилә социаль шартларында, авыр тормыш хәлендәге балалар һәм яшьләр, шулай ук медицинага бәйле булмаган наркотикларны куллану куркынычы янаган затлар өчен билгеләнгән.

## III. Программа чаралары исемлеге

Программа чаралары, шулай ук Программаның төп чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары исемлеге әлеге Программага кушымта нигезендә бирелгән.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау буенча Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен 135 мең сум, Әлки муниципаль районы бюджеты акчасы кирәк, шул исәптән:

2021 елда-45 мең сум,

2022 елда-45 мең сум.

2023 елда-45 мең сум

Программаны финанслау чыганагы-Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, Әлки муниципаль районы бюджеты акчалары.

## V. Программаны тормышка ашыру механизмы һәм аның үтәлешен контрольдә тоту

Чараларны финанслау әлеге Программа өчен җаваплы һәм аны үтәүче җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм учреждениеләр аша гамәлгә ашырыла.

Программаның үтәлешенә гомуми контрольне Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия белән килештереп максатчан күрсәткечләрне һәм программа чаралары буенча чыгымнарны, Программаны гамәлгә ашыру механизмын, башкаручылар составын ачыклаучы һәм аларны үзгәртү буенча тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советына кертүче Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

Башкаручылар (җаваплылык үзәге) дәүләт ихтыяҗлары өчен конкурс нигезендә урнаштырылучы заказлар шартнамәсен алдан тикшерүне һәм

алга таба Программаның конкрет чараларын үтәүгә килешүләр төзеп заказларны урнаштыруны оештыралар.

Программа чараларын тормышка ашырганнан соң, Программаны башкаручылары Әлки муниципаль районы Башкарма комитетына билгеләнгән формада чараларның үтәлеше турында квартал саен хисап тапшыралар.

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында наркотикларга каршы комиссия утырышында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Программаны үтәү һәм бер ел эчендә финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында хәбәр итә.

## VI. Программаның социаль һәм икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеге наркотикларның законсыз куллану масштабын, наркомания белән авыручылар санын, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр кулланудан үлем нәтиҗәләрен киметү, наркотикларның законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү, наркотиклар куллануның тискәре нәтиҗәләре турында халыкка мәгълүмат җиткерүне арттыруда чагыла.

Программаны тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре түбәндәгеләр белән билгеләнәчәк:

бу өлкәдә адекват һәм үз вакытында чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында наркотикларга каршы хәлнең үсеш динамикасы турында тулы мәгълүмат алу;

наркотиклаштыруны профилактикалау һәм наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә белгечләрнең һөнәри компетенцияләрен арттыру

яшүсмерләр һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру, психоактив матдәләр кулланудан баш тарту;

наркотикларга бәйле, наркотиклар куллануны туктаткан кешеләргә социаль-психологик, шул исәптән аларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү системасын киңәйтү;

наркотикларга бәйле кешеләр өчен мотивация, дәвалау һәм реабилитация программаларын камилләштерү;

наркотиклар контрабандасын булдырмау, наркоҗинаятьнең оешкан формаларына каршы тору буенча хокук саклау органнары эшен активлаштыру.

2021-2023 елларга районның наркотикларга<br>каршы максатчан Программасына<br>Кушымта

2021-2023 елларга районның наркотикларга каршы максатчан программасын тормышка ашыру буенча чаралар

П Л А Н Ы

| Максатның аталышы | Бурыч атамасы | Төп чара атамасы | Үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Еллар буенча индикаторларның әһәмияте | | | Еллар буенча финанс белән тәэмин итү | | | Баш башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2021 | 2022 | 2023 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 2023 елда 2020 елга карата районда медицинага бәйле булмаган наркотикларны законсыз куллану масштабларының кимүе | 1.Хокук саклау органнарының наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча көчләрен активлаштыру | 1.1 Наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш эшчәнлеген тәэмин итүче эш биналарына ремонт ясау | 2023 | Тикшерелгән наркоҗинаятьләр саны-процент | 101 | 101, 1 | 101, 2 | Республика бюджеты | | | |
| | | 1.2 тәмәке катнашмаларының таралуына каршы торуга юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыру | 2021-2023 | | | | | Республика бюджеты | | | |
| | | 1.3 наркотиклы үсемлекләрнең үсүенең ачыкланган чыганакларын | 2021-2023 | | | | | Агымдагы финанслау | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | механик һәм химик ысуллар белән юкка чыгаруны оештыру | | | | | | | | | |
| | 2. Дәвалау һәм реабилитацион ярдәм системасын камилләштерү | 2.1 Эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан китерелгән наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр кулланучы затларга карата медицина тикшерүләрен үткәрүне оештыру турында диагностик тестлар алу | 2021-2023 | Наркоманиядән дәваланган һәм реабилитация үткән авыручылар санын арттыру | 104 | 105 | 106 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | |
| | | 2.2 наркотикларга бәйле кешеләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү, шул исәптән аларда дәвалауга мотивация формалаштыру | 2021-2023 | | | | | Агымдагы финанслау | | | |
| | | 2.3 Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр куллану | 2021-2023 профилактик наркология | | | | | Республика бюджеты | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | предметына укучыларга, чакырылу яшендәге затларга профилактик медицина тикшерүе үткәрү | тикшерүен узган укучылар һәм чакырылу яшендәге затлар саны | | | | | | |
| | | 2.4 социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә, наркология кабинетында наркотизациянең башлангыч стадияләрендә, реабилитация һәм ресоциализацияләүне, социаль – психологик чаралар үткәрүне тәэмин итәргә | 2021-2023 | | | | | **Агымдагы финанслау** | |
| | 3. Балаларны һәм яшьләрне спорт, физик тәрбия һәм спорт түгәрәкләрендә даими шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру | 3.1 Наркотикларга каршы профилактик проектларның республика конкурсларында катнашу | 2021-2023 | **Физик тәрбия һәм спорт түгәрәкләрендә даими рәвештә шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр санын арттыру, процентларда** | 109 | 110 | 111 | **Агымдагы финанслау** | |
| | | 3.2. Наркотикларга каршы проектларны тормышка | 2021-2023 | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ашыруны дәвам итү, шул исәптән: | | | | | | | | | |
| | | "Наркотикларсыз мәктәп территориясе" | | | | | | | | | |
| | | «Мин спортны начар гадәтләргә альтернатива буларак сайлыйм» акциясе | | | | | | | | | |
| | | «Мөстәкыйль балалар» | | | | | | 5,0 | 5,0 | 5,0 | |
| | | 3.3 Белгечләрнең халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау проблемалары буенча конференцияләрдә, утырышларда, семинарларда катнашуы | 2021-2023 | Наркотикларга каршы эшне оештыру һәм үткәрүдә белемнәре, осталыклары һәм күнекмәләре булган белгечләр санын арттыру, процентлар | 101 | 102 | 103 | Агымдагы финанслау | | | |
| | | 3.4 Наркотикларга каршы эшне оештыру һәм үткәрү мәсьәләләре буенча белгечләрнең квалификациясен | 2021-2023 | | 101 | 102 | 103 | Республика бюджеты | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | күтәрү | | | | | | |
| | 4.Халыкта наркотиклар куллануга тискәре караш һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру | 4.1 Наркотикларга каршы киномарафоннар үткәрү | 2021-2023 | Сәламәт яшәү рәвешенә йөз тоткан балалар һәм яшьләр саны арттыру - процент | 104 | 105 | 106 | Агымдагы финанслау | «Мәдәният бүлеге» МКУ |
| | | 4.2 Наркотикларга каршы республика конкурсларында катнашу | 2021-2023 | | | | | | «Мәдәният бүлеге» МКУ, «Мәгариф бүлеге» МКУ, яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге (ЯСһСБ) |
| | | 4.3 Наркотикларга каршы акция: «Наркотикларсыз тормыш» | 2021-2023 | | | | | | «Мәдәният бүлеге» МКУ |
| | | 4.4 Наркотикларга каршы чаралар үткәрү өчен мәдәният бүлегенең матди-техник базасын яхшырту | 2021-2023 | | | | | | «Мәдәният бүлеге» МКУ |
| | | 4.5 Авыл мәдәният йортында, район мәдәният йортында наркотикларга каршы спектакльләр кую һәм күрсәтү | 2021-2023 | | | | | | «Мәдәният бүлеге» МКУ |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 4.6 Наркотикларга каршы эшчәнлекне мәгълүмати һәм методик тәэмин итү: | 2021-2023 | | | | | | ЯСһСБ Район газетасы |
| | | 4.6.1 Сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга һәм психоактив матдәләр куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру буенча массакүләм мәгълүмат чаралары эшен оештыру | 2021-2023 | | | | | | Район газетасы, ЯСһСБ, сәркәтип Наркотикларга каршы комиссия |
| | | 4.6.2 Әлки МР сайты эшен тәэмин итү | 2021-2023 | | | | | | Сайт администраторы |
| | | 4.6.3 Наркоманияне профилактикалау буенча методик әдәбиятны һәм күрсәтмә агитация чараларын оештыру һәм тарату | 2021-2023 | | | | | | «Мәдәният бүлеге» МКУ |
| | | 4.6.4 Район | 2021-2023 | | | | | | «Мәдәният |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | китапханәләрендә наркотикларга каршы темага күргәзмәләр үткәрү | | | | | | | бүлеге» МКУ |
| | | 4.6.5 Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге учреждениеләрендә наркотикларга каршы профилактика эшен оештыру һәм үткәрү | 2021-2023 | | | | | | ЯСһСБ |
| | 5.Наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив, хокукый тәэмин итүне камилләштерү | 5.1 Дини конфессияләр вәкилләренең наркотикларга каршы эштә катнашуы | 2021-2023 | | | | | Агымдагы финанслау | |
| | | 5.2 Наркотик кулланудан туктаган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм итү | 2021-2023 | | | | | Республика бюджеты | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әлки МР буенча социаль яклау бүлеге |

Барысы: ел саен - 45 мең, барлыгы - 135 мең сум.